ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.05.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1025**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2017-2018 елларның ягып җылыту чорын тәмамлау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 989 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

2005 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы нормативтан югарырак(+8°С) булу сәбәпле, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2017-2018 елларның ягып җылыту чорын тәмамлау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 989 номерлы карарының 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләр кертергә: «2018 елның 30 апреленнән» дигәнне «2018 елның 03 маеннан» белән алыштырырга.
2. Тышкы һава температурасы кискен төшкән очракта, җылылык буенча хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә, биналар һәм торак биналар эчендә җылылык белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүче инженерлык челтәрләренә җылылык җибәрүне күздә тотарга.
3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru ), хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль

районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында, «Зеленый Дол» һәм «Яшел Үзән» басмаларында. урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин